Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2015 ел №8

"Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә социаль файдалану шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынының гомуми мәйданы күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогыбашкарма комитеты КАРАР БИРӘМ:

1. «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гаиләнең бер әгъзасына исәплләгәндә социаль куллану шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынының гомуми мәйданын 18 кв. метр күләмендә билгеләргә.

2. Әгәр гражданның исәпкә алынган гаризасында торак урынының гомуми мәйданыннан кимрәк билгеләнгән күләмнән кимрәк, шул исәптән бирү нормасыннан кимрәк булган гомуми мәйданын бирүгә риза булуы күрсәтелсә, бирелә торган торак урынының гомуми мәйданы күләме билгеләнгән күләмнән кимрәк, шул исәптән бирү нормасыннан кимрәк, ләкин хисап нормасыннан ким булмаска мөмкин.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Җәлил ш.т. п., Җиңү еллары ур., 6 йорт; тҗәлил поселогы, Әхмәдиев ур., 20 йорт территорияләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Калимуллина